**ИСПОЛКОМ АПАСТОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422350, пгт. Апастово, улица Советская, д.2

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

422350,Апас штп. , Совет урамы, 2 йорт

тел.: (84376) 2-13-52, факс: 2-19-27, e-mail: apast@tatar.ru, http://apastovo.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

№ 234 ... 10.06.2020

# Объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Күпфатирлы йортларны һәм башка күчемсез милек объектларын өлешле төзүдә катнашу һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында "Федераль законга һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында" 2019 елның 27 июнендәге 151-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Башкарма комитеты **карар бирә:**

1.Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Башкарма комитетының «архитектура һәм шәһәр төзелеше өлкәсендә административ регламентларны раслау турында» 2018 елның 27 ноябрендәге 261 номерлы карары белән расланган объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына (6 нчы кушымта) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.3 пунктны түбәндәге эчтәлекле абзацлар белән тулыландырырга:

«Башкарма комитет, РФ Шәһәр төзелеше кодексының 51 статьясындагы 12 өлешендә һәм 52 статьясындагы 3.3 өлешендә каралган очракларда, капиталь төзелеш объектларын төзү, реконструкцияләү этапларына карата күрсәтелгән рөхсәтләрне бирә».

Капиталь төзелеш объектын төзү, үзгәртеп кору этабына карата объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт бирү турында гариза бирелгән очракта, РФ Шәһәр төзелеше кодексының 55 статьясындагы 3 өлешенең 4, 6-12 пунктларында күрсәтелгән документлар капиталь төзелеш объектын төзүнең, реконструкцияләүнең тиешле этабына кагылышлы өлешендә рәсмиләштерелә. Күрсәтелгән очракта капиталь төзелеш объектын төзү, реконструкцияләү этабына карата объектны эксплуатациягә кертүгә рөхсәт бирү турындагы гаризада капиталь төзелеш объектын төзү, реконструкцияләү этабына карата (булган очракта) элек тапшырылган рөхсәтнамә күрсәтелә.

Объектны файдалануга тапшыруга рөхсәтнамә, объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт бирү турында гаризада күрсәтелгән очракта, электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә бирелә.";

2.4 пунктны киләсе редакциядә бәян итәргә:

«Муниципаль хезмәт күрсәтү вакыты, гариза бирү көнен дә кертеп[1], биш көн.

Объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт дубликатын бирү-өч көн.

Муниципаль хезмәт күрсәтү вакытын туктатып тору каралмаган.

Муниципаль хезмәт нәтиҗәсе булган документны мөрәҗәгать иткән көнендә гамәлгә ашырыла.

Муниципаль хезмәт нәтиҗәсе булган документны юллау гаризада күрсәтелгән элемтә ысулын кулланып (почта аша яки электрон адреска) муниципаль хезмәт нәтиҗәсен рәсмиләштерү һәм теркәү көнендә гамәлгә ашырыла".

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Апас муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше буенча урынбасары А.М. Хәсәновка йөкләргә.

**Җитәкче** **А. А. Тугушев**

---